| 14. | Авыл хуҗалыгы — икътисадның мөһим өлкәсе генә түгел, тормыш рәвеше дә. Аның телне, мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне саклап калуда өлеше бик зур.<br>Без авылга һәрчак булышып килдек, аңа алга таба да ярдәм итәрбез. Күпләгән республика программасы шул максатка юнәлгән.<br>Авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген арттырырга кирәк. Бүгенге көндә бертигез мөмкинлекләре булган районнар һәм хуҗалыклар гаять төрле күрсәткечләргә ирешә.<br>Мисал өчен, сөрүлек җирләре мәйданы Кукмара һәм Балтач районнарыннан әллә ни аерылмый торган Лениногорск, Чүпрәле һәм Апас районнары 1 гектардан акчалата керемне 2 тапкырга кимрәк ала.<br>Яисә Кукмара районының Вахитов исемендәге хуҗалыгында барлыгы 2,5 мең сыердан тәүлегенә 77 тонна сөт савып алына. Бу күрсәткеч савым сыерларының баш саны 2 тапкырга күбрәк булган Әгерҗе районы белән чагыштырганда артыграк. | 14.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азыктөлек сәясәте комитетының һәм «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азыктөлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азыктөлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын үтәү турында»гы мәсьәләне карау | квартал саен | Т.Г. Һадиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15. | Агросәнәгать комплексының алга таба үсеше авыл хуҗалыгы продукциясен тирәнтен эшкәртүгә юнәлтелгән булырга тиеш.<br>Бүгенге көндә өстәмә бәянең шактый зур өлеше республикабыздан читтә билгеләнә. Моның нәтиҗәсендә керемебезнең күпмедер күләме кулдан китә. | 15.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының һәм «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының авыл хуҗалыгы продукциясен сатуының икътисадый нәтиҗәлелеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында»гы мәсьәләне карау | 2019 елның II кварталы | Т.Г. Һадиев |
| | | 15.2. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре проблемалары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау | ел дәвамында | Х.Г. Миргалимов |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 16. | Хуҗалык итүнең кече формалары һәм шәхси хуҗалыклар тарафыннан җитештерелгән продукциягә ихтыяҗ шулай ук югары дәрәҗәдә саклана.<br>Бакчасында яшелчә үстерә һәм мал-туар асрый торган кеше үзе өчен генә түгел, ә башкалар өчен дә игелекле эш башкара. Без мондый кешеләрнең хезмәтен бәяләргә һәм аларга кулдан килгәнчә ярдәм күрсәтергә тиеш.<br>Әлеге максатларда республика авылларында хуҗалык итүнең кече формалары эш активлыгын арттыруга гына да ел саен 2 млрд. сум акча бүлеп бирелә. Бу – 20 гә якын ярдәм итү чарасы дигән сүз. | 16.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының һәм «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында»гы мәсьәләне карау | 2019 елның III кварталы | Т.Г. Һадиев |
| 17. | Авыл хуҗалыгы кооперативларын һәм агропаркларны үстерү – актуаль сорау. Авылда бер кешегә сату базарына чыгу кыен, тулы бер система кирәк. Куллanучылар кооперациясе әлеге мәсьәләне хәл итә.<br>Инициативалы кешеләрне табу һәм аларга ярдәм итү – район һәм авыл җирлекләре башлыклары бурычы.<br>Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына Татарстан Республикасы | 17.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының һәм «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Муниципаль берәмлекләр советы белән берлектә чимал эшкәртү, продуктны «кырдан кибет киштәләренә» җиткерү өчен районнар арасында кооперацияне җайга салу шарт. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, шулай ук район башлыкларының эшендә төп өстенлекләрнең берсе булып авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең тулысынча файдаланылуын һәм аларның саклануын тәэмин итү тора. | чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында «Авылларда кулланучылар кооперациясен үстерүгә юнәлдерелгән чаралар турында»гы мәсьәләне карау | 2019 елның IV кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе |
| | | 17.2. «Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең проблемалары һәм аларны чишү юллары» темасына «түгәрәк өстәл» уздыру | 2019 елның апреле | Х.Г. Миргалимов |
| 18. | Коррупциягә каршы көрәшү сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре актуальлеген югалтмый. Бу юнәлештә гаять зур эш башкарыла. Һәм без аны дәвам итәчәкбез. Беркем дә буш өметләр белән яшәмәсен! | 18.1. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында һәм җирле үзидарә органнарында норматив хокукый актларга коррупциягә каршы экспертиза уздыру турында»гы контроль мәсьәләне карау | 2018 елның апреле | Ш.Ш. Яһудин |
| | | 18.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чикләүләр, тыюлар буенча, шулай ук коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны, | ел дәвамында | ТР ДС Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | шул исәптән бүләкләр бирү һәм алу, ришвәт бирү һәм кабул итүгә кагылышлы чикләүләрне үтәү буенча аңлату чараларын һәм башка чараларны гамәлгә ашыру | | |
| | | 18.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратында Мониторинг-К формасы буенча коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру турында хисап әзерләү, «Ачык Татарстан» мәгълүмат системасында күрсәткечләр кертү һәм бастырып чыгару | квартал саен | ТР ДС Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге |
| | | 18.4. 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының коррупциягә каршы программасы чараларын үтәү | ел дәвамында | ТР ДС Аппараты |
| | | 18.5. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру | ел дәвамында | ТР ДС Аппаратының Хокук идарәсе |
| | | 18.6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары һәм коррупциягә каршы көрәш эшләрен җайга салу комиссиясе тарафыннан бергәләп уздырыла торган тематик утырышлар | ел дәвамында | ТР ДС депутатлары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19. | Сәламәтлек саклау учреждениеләрен модернизацияләүгә 30 млрд. сумнан артык акча бүлеп бирелде. Бу – фельдшер-акушерлык пунктлары, табиблык амбулаторияләре, ашыгыч медицина ярдәме станцияләре төзеләчәк дигән сүз.<br>Моннан тыш, быел без Татарстанда илебездә тиңе булмаган программаны үтәүне төгәллибез. Шуның нәтиҗәсендә республикада 197 поликлиника төзекләндерелде һәм заманча җиһазландырылды. | 19.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетының һәм Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында «Амбулатор этапта пациентларга югары технологияле медицина ярдәме күрсәткәннән соң аларга тиешенчә медицина тикшеренүен тәэмин итү өлешендә медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турында»гы мәсьәләне карау | 2019 елның июне | С.М. Захарова |
| 20. | Спорт инфраструктурасын төзүдә бик күп эш башкарылды. Бөтен республика буенча меңгә якын универсаль спорт мәйданчыгы, 71 спорт залы, 62 бассейн, 17 яңа боз сарае, 27 чаңгы базасы төзелде.<br>Бу исә сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга бик яхшы этәргеч бирә. Республикада физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең саны икеләтә, ягъни 43 % тан артты. | 20.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Мәгариф оешмаларының (спорт мәктәпләре, гомуми белем бирү оешмалары, югары уку йортлары) спорт инфраструктурасын үстерү турында»гы мәсьәләне карау | 2019 елның марты | С.М. Захарова |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 21. | Хәзер һәрбер районда заманча социаль, мәдәни һәм спорт объектлары бар.<br>Берсүзсез, гаять зур эш башкарылды. Быел гына да республикада 44 млрд. сумга 38 программа гамәлгә ашырыла.<br>Без, һичшиксез, бу эшне дәвам итәчәкбез. Ул системалы рәвештә, һәр объект буенча 3 елга исәпләнгән программалар нигезендә башкарылачак.<br>Программаларны формалаштыруның сыйфатына аеруча игътибар бирергә кирәк. Аларның синхронлыгын, шулай ук әлеге объектларның үзләрен рациональ файдалануны тәэмин итәргә кирәк.<br>Министрлык һәм ведомство җитәкчеләре, район башлыклары капиталь акча салу программаларын формалаштыру һәм аларны үтәү өчен шәхсән җаваплы. | 21.1. Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларын һәм аларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрне карау (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары карамагындагы мәсьәләләр өлешендә)<br><br>21.2. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау | ел дәвамында<br><br>ел дәвамында | ТР ДС комитетлары рәисләре<br><br>Ю.З. Камалтынов, Х.Г. Миргалимов, ТР ДС Аппаратының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге |
| 22. | Белем, күнекмәләр, тәҗрибә туплау, халык сәламәтлеген ныгыту һәм нәтиҗәле хезмәт өчен уңай мохит формалаштыру аша кеше капиталын арттыру гаять мөһим бурычларның берсе булып кала.<br>Бирегә төп роль мәгариф өлкәсенә бирелә.<br>Соңгы 8 елда әлеге тармакның берләштерелгән бюджеты 3 тапкырга диярлек артты.<br>Әлбәттә, мәгариф өлкәсенә тотылган чыгымнар – дәүләт өчен гадәти социаль йөкләмәләр генә түгел. Бу, безнең зур нәтиҗәләр өмет итеп, киләчәккә инвестицияләребез булып тора.<br>Без республикада яшәүче һәр кешенең, аның барлык мөмкинлекләрен исәпкә алып, үсешенә ярдәм итәргә, балаларга киләчәккә юнәлеш бирергә бурычлы. | 22.1. Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында) | 2019 елның I кварталы | Р.И. Вәлиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Яшь буын вәкилләренең сәләтләрен ачу һәм конкурентлык өстенлекләрен ачыклау буенча бербөтен система булдыру зарур.<br>Мәгариф системасының барлык баскычлары өчен төп тема булып балалар бакчасыннан һәм башлангыч сыйныфлардан ук балаларга дөрес һөнәри юнәлеш бирү тора. Биредә остазлык институты гаять әһәмиятле урын алып тора һәм аны актив рәвештә үстерергә кирәк. Югары уку йортлары, фәнни коллективлар һәм уңышлы компанияләр мәгариф оешмаларының партнерлары булырга тиеш. | | | |
| 23. | Иҗади, креатив яшьләр аерым игътибар сорый. Алар алда торган бурычларны стандарт булмаган алымнар белән хәл итә, яшь буын фикеренә йогынты ясый.<br>Без алга таба да креатив индустрияләр үзәкләрен үстерергә, аларның вәкилләрен гамәлдәге мәдәни, мәгариф һәм яшьләр үзәкләре эшенә җәлеп итәргә, яңа иҗат продуктларын булдыру һәм тарату эшенә булышлык күрсәтергә тиеш.<br>Республикабызда талантлы яшьләр күп. | 23.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасының талантлы яшьләр белән эшләү һәм яшьләр арасында парламент дебатлары буенча чаралар уздыру инициативаларын гамәлгә ашыруда ярдәм итү | ел дәвамында | С.М. Захарова |
| | | 23.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасының яңа составын булдыру | 2019 елның IV кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе |



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 24. | Халыкның гомер озынлыгын арттыру (илебез Президенты 2024 елга кадәр 78 яшь дип билгеләгән), кан әйләнеше системасы авыруларыннан һәм яман шеш авыруларыннан үлүчеләрнең санын киметү сәламәтлек саклау системасы өчен киләсе елларда өстенлекле бурыч булып тора.<br>Әлеге максатларда республикада тагын башлангыч дәрәҗәдә кан тамырларын тикшерү буенча ике үзәк ачу, гамәлдәге 18 үзәкне яңадан җиһазландыру, Республика онкология диспансерын реконструкцияләү, Чаллы һәм Әлмәт шәһәрләрендә аның ике филиалын, шулай ук Балалар онкогематология үзәген төзү планлаштырыла. | 24.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетының һәм Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенең уртак утырышында «Татарстан Республикасында онкологик ярдәм оештыру турында»гы мәсьәләне карау | 2019 елның октябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе |
| 25. | Моннан тыш, олы яшьтәге гражданнар өчен махсуслаштырылган медицина ярдәме үзәге – гериатрия хезмәте оештыру ихтыяҗы килеп туды. | 25.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Татарстан Республикасында геронтология хезмәтенең һәм гериатрия ярдәменең торышы һәм аларны үстерү турында» 2018 елның 13 июнендәге 34/1 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты карары тәкъдимнәрен башкару хакында»гы мәсьәләне карау | 2019 елның июле | С.М. Захарова |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 26. | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле тәкъдимнәр әзерләүне йөклим.<br>Сәламәтлек саклау өлкәсендә профилактика һәм диспансеризация төп рольне уйнарга тиеш.<br>Ел саен бу максатка республика якынча 2 млрд. сум бүлеп бирә.<br>Диспансеризация авыруны иртә ачыклауга, вакытында диспансер исәбенә куюга, квалификацияле дәвалауга юнәлгән булырга тиеш. Шуңа күрә аның сыйфатын күтәрү кирәк.<br>Моннан тыш, Хөкүмәткә һөнәр берлекләре белән бергәләп предприятиеләрдә аларның үз хезмәткәрләренең сәламәтлеген саклау өчен профилактик чаралар уздыру буенча бурычларын үтәү-үтәмәүләрен тикшерү эшен дәвам итәргә кирәк. | 26.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Хезмәткә сәләтле яшьтәге халыкның сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау (Татарстан Республикасындагы предприятиеләрнең берсе мисалында) | 2018 елның декабре | С.М. Захарова |
| 27. | Балаларның җәйге сәламәтләндерү ялы мәсьәләсенә аерым тукталып үтәсем килә. Киләсе елдан без өч елга исәпләнгән яңа шәһәр яны балалар сәламәтләндерү лагерьларын яңарту программасын башлап җибәрәбез, әлеге лагерьларның саны республикада – 146. Аларның бик күбесенең торышы канәгатьләндерерлек түгел.<br>Әлеге программаны гамәлгә ашыру яшь буынга ял итү өчен заманча, уңайлы шартлар тудыру мөмкинлеге бирәчәк.<br>Программа биналарны капиталь төзекләндерү һәм реконструкцияләү, заманча күпфункцияле модуль үзәкләре һәм корпуслар төзү, мәдәни-спорт мәйданчыклары булдыру, коммуналь челтәрләрне яңарту, эчке юлларны һәм лагерьларга илтә торган юлларны төзү һәм реконструкцияләүне үз эченә ала.<br>Спорт, иҗат һәм балалар үсеше өчен кирәкле башка юнәлешләрдә шөгыльләнү өчен шартлар булдыруга аерым игътибар биреләчәк.<br>Тагын бер кат басым ясап әйтәм, балаларны сәламәтләндерү ул – комплекслы бурыч. Монда әһәмияте булмаган нәрсәләр юк. Сүз безнең балаларыбызның киләчәге турында бара, ә бу инде тулаем республиканың киләчәге дигән сүз. | 27.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялын оештыру турында»гы мәсьәләне карау | 2019 елның мае | С.М. Захарова |
| 28. | | 28.1. Татарстан Республикасы Президентының 2019 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат берләшмәләре тарафыннан гамәлгә ашыру (аерым планнар буенча) | ел дәвамында | Ю.З. Камалтынов,<br>Х.Г. Миргалимов,<br>Р.З. Закиров,<br>Т.П. Ларионова |

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘЛӘРЕ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 904. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 499-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 63, 64 статьялары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 499-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кабул итәргә.

2. «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 499-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка комитетларына, аларны закон проекты буенча ярдәмче башкаручылар итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү өчен закон чыгару инициативасы хокукының башка субъектларына, шулай ук бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

3. Ярдәмче башкаручы комитетлар «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 499-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектының түбәндәге аерым нигезләмәләрен карауны гамәлгә ашыра дип билгеләргә:



Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты — Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Гомумдәүләт мәсьәләләре», «Дәүләт бурычына һәм муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү», «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына гомуми характердагы бюджетара трансфертлар» бүлекләрен;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты — Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Милли оборона», «Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге» бүлекләрен, «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегенең «Суд системасы» бүлекчәсен;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты — Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Милли икътисад», «Торак-коммуналь хуҗалык» бүлекләрен;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты — Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Әйләнә-тирә мохитне саклау» бүлеген, «Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге» бүлегенең «Халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, гражданнар оборонасы» бүлекчәсен, «Милли икътисад» бүлегенең «Минерал-чимал базасын торгызу», «Авыл хуҗалыгы һәм балыкчылык», «Су хуҗалыгы», «Урман хуҗалыгы» бүлекчәләрен;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты — Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Сәламәтлек саклау», «Социаль сәясәт», «Физик культура һәм спорт» бүлекләрен, «Мәгариф» бүлегенең «Яшьләр сәясәте» бүлекчәсен;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты — Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары классификациясенең «Мәгариф», «Культура, кинематография», «Массакүләм мәгълүмат чаралары» бүлекләрен, «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегенең «Фундаменталь тикшеренүләр» бүлекчәсен.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасының бәяләмәләрен 2018 елның 5 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты 2018 елның 10 октябренә кадәр «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Респу-

бликасы бюджеты турында» 499-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектына җыелма бәяләмә әзерләргә, күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 18 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына 2018 елның 8 октябрендә 14 сәгатьтә «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 499-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты буенча парламент тыңлауларын үткәрүне йөкләргә.

7. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы**
**Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2018 елның 1 октябре
№ 535-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 905. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 500-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 500-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карауга кабул итәргә.

2. «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 500-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына, аны закон проекты буенча башкарышучы итеп билгеләп, искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының башка комитетларына, депутат берләшмәләренә, закон чыгару инициативасы хокукына ия башка субъектларга, шулай ук бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 18 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы**
**Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2018 елның 1 октябре
№ 536-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 906. Д.В. Әхмәтҗановaны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесенең 10 нчы номерлы медик-социаль экспертиза бюросы җитәкчесе — медик-социаль экспертиза табибы Әхмәтҗанова Динә Вил кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 2 октябре
№ 537-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 907. Э.Т. Әхмәдуллинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесенең 17 нче номерлы медик-социаль экспертиза бюросы җитәкчесе — медик-социаль экспертиза табибы Әхмәдуллина Эльмира Таһир кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 2 октябре
№ 538-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 908. Л.Д. Муратованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы Муратова Ләйсән Дамир кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 2 октябре
№ 539-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 909. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Т.Г. Һадиев, Р.Р. Гайзатуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 501-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны билгеләү мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә) алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 501-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 28 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы**
**Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2018 елның 2 октябре
№ 540-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 910. С.В. Сапрыкинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының оператив эзләү мәгълүматы бүлегенең мәгълүмат-аналитика бүлекчәсе баш белгече Сапрыкина Светлана Владимировнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 8 октябре
№ 541-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 911. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты И.Ә. Касыймов тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 502-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (электр тапшыру линияләренә һәм аларның аерылгысыз технологик өлеше булып торган корылмаларга карата киметелгән салым ставкалары билгеләү өлешендә) алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 502-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 3 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы**
**Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2018 елның 8 октябре
№ 542-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 912. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты И.Ә. Касыймов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына үзгәреш кертү хакында» 504-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (терминологияне федераль законнарга туры китерү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына үзгәреш кертү хакында» 504-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 5 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы**
**Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2018 елның 8 октябре
№ 543-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 913. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 4 пунктының 1 пунктчасы үз көчен югалтуын тану хакында» 505-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (лизингка тапшырылган Россия Федерациясендә җитештерелгән һәм тиешле экологик нормаларга туры килә торган йөк автомобильләренә һәм автобусларга карата салым ташламасын бетерү өлешендә) алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 4 пунктының 1 пунктчасы үз көчен югалтуын тану хакында» 505-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 1 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов**

Казан шәһәре,
2018 елның 9 октябре
№ 544-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 914. Д.Ә. Шәрәфетдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кerткән өчен Федераль ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы урынбасары Шәрәфетдинов Динар Әлфис улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 октябре
№ 545-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 915. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 26 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 503-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (башкарма хакимият органнарының хезмәтне саклау өлкәсендәге вәкаләтләре кабатлануны булдырмау һәм биомедицина күзәнәк продуктлары әйләнеше өлкәсендә дәүләт тикшереп торуының яңа тәртип кертү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 26 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 503-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук бәяләмә бирү өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасына һәм юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты күрсәтелгән закон проектын 2018 елның 5 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 октябре
№ 546-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 916. Г.Ш. Сабитованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Ремдизель» акционер җәмгыяте «Махсус автомобильләр заводы» аерымланган бүлекчәсенең комплект эшләнмәләрен һәм материалларын китерүне планлаштыру бүлегенең кооперацияне планлаштыру төркеменең планлаштыру буенча әйдәүче икътисадчысы Сабитова Гөлнара Шамил кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 октябре
№ 548-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 917. И.В. Кротованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Ремдизель» акционер җәмгыятенең сатып алулар һәм логистика департаменты логистика һәм склад хуҗалыгы хезмәтенең хуҗалык мөдире Кротова Ирина Владимировнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 октябре
№ 549-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 918. Р.М. Бакировны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Ремдизель» «Махсус автомобильләр заводы» акционер җәмгыяте аерым бүлекчәсенең автомобильләр җыю цехының автомобильләрне җыеп бетерү һәм тапшыру участогының алтынчы разрядлы механик җыю эшләре слесаре Бакиров Рафис Марс улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 октябре
№ 550-РК

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

## 919. Н.Р. Исмәгыйлевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татар мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш керткән өчен Ташкент шәһәренең Татар иҗтимагый мәдәни-агарту үзәге активисты Исмәгыйлев Назыйм Рафин улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 октябре
№ 551-РК

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

## 920. С.Р. Юнееваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татар мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә зур өлеш керткән өчен Ташкент шәһәренең Татар иҗтимагый мәдәни-агарту үзәге активисты Юнеева Сабрина Руфат кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 октябре
№ 552-РК



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

## 921. И.М. Айтугановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Казаньоргсинтез» гавами акционер җәмгыяте ветераны Айтуганов Ил Мәннаф улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 октябре
№ 553-РК

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

## 922. Л.А. Ивановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Казаньоргсинтез» гавами акционер җәмгыяте ветераны Лев Александрович Ивановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 октябре
№ 554-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 923. А.Ю. Афанасьевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы хәрби комиссары Афанасьев Александр Юрьевичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 10 октябре
№ 555-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 924. Б.К. Корбановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны Корбанов Барый Корбангали улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 11 октябре
№ 556-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 925. С.К. Сабировны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны Сабиров Салихҗан Кадыйрҗан улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 11 октябре
№ 557-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 926. А.Н. Митрясовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия ЭЭМның Яңа Чишмә районы буенча бүлегенең җинаятьчеләрне эзләү бүлеге башлыгы Александр Николаевич Митрясовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 11 октябре
№ 558-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 927. М.Н. Хәкимовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия ЭЭМның Чаллы шәһәре буенча идарәсенең «Автозаводск» 1 нче номерлы полиция бүлегенең җинаятьчеләрне эзләү бүлегенең территориягә хезмәт күрсәтү бүлекчәсенең өлкән оперуполномоченные Хәкимов Марсель Нәҗип улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 11 октябре
№ 559-РК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 928. Э.Ф. Яхинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Эчке эшләр министрлыгының Зәй шәһәре бүлеге җинаятьчеләрне эзләү бүлегенең шәхескә каршы җинаятьләрне ачу төркеме оперуполномоченные Яхин Эльвир Фазыл улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2018 елның 11 октябре
№ 560-РК



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### 929. В.Г. Бәхтигәрәеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

